ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАТАР ЯМАЛЫ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423753, Татар Ямалы авылы,
Ленин ур.,6 нчы йорт.
Тел/факс 5-75-19

СОВЕТ ТАТАРСКО-
ЯМАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423753, село Татарские Ямалы,
ул.Ленина,дом 6.
Тел/факс 5-75-19

**КАРАР**
**№ 28**

**РЕШЕНИЕ**
**“02” октябрь 2019 ел**

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Ямалы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыены үткәрү һәм әзерлек тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында**

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ санлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турындагы Федераль законга үзгәрешләр кертү турында” 2019 елның 1 маендагы 87-ФЗ номерлы Федераль Закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Ямалы авыл җирлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Татар Ямалы авыл җирлеге Советы

карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Ямалы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыены үткәрү һәм әзерлек тәртибе турындагы нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Ямалы авыл җирлеге Советының 13.09.2018 № 30 санлы “Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Ямалы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыены үткәрү һәм әзерлек тәртибе турындагы” карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Актаныш муниципаль районы Татар Ямалы авыл җирлегенең рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.
4. Аның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Татар Ямалы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татар Ямалы авыл җирлеге башлыгы Д.Ф.Валиев